Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Яңа Кәшер авыл Советы

# КАРАРЫ

26 май 2022 ел №42

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 79 номерлы « Яңа Кәшер авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Яңа Кәшер авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Яңа Кәшер авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл Советының 2014 елның 05 ноябрендә кабул ителгән 79 номерлы «Яңа Кәшер авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Яңа Кәшер авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

6 пунктның в) пунктчасында «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга;

13 пунктта «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Яңа Кәшер авылы, Тавабил урамы, 153 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Яңа Кәшер
авыл җирлеге башлыгы Л.М. Гыйниятуллина